**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 29 октябре

№12

Аерым муниципаль норматив хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында

Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә норматив-хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан Бишнә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Бишнә авыл җирлеге советы карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- 2014 елның 28 февралендәге 150 номерлы «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары»;
- Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының Бишнә авыл җирлеге Советының 2014 елның 28 февралендәге 150 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында»гы 2018 елның 22 ноябрендәге 205 номерлы карары;
- «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджеты турында»гы 2018 елның 17 декабрендәге 207 номерлы карары»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составында Зеленодольск муниципаль районы информацион сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» информацион телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда урнаштырырга: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт ( авыл мәдәният йорты бинасы).

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе:** **И.М.Фатхуллин**